**Азнакай муниципаль районы**
**Тымытык авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Тымытык авылы № 52-96 «21» сентябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының 2016 елның 10 июнендәге 32-14 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (15.11.2016 № 39-22, 25.09.2017 № 57-43, 12.02.2018 №52-74, 30.12.2019 №90-146, 14.04.2020 №95-157, 12.10.2021 №22-38, 07.04.2023 №45-85 карарлар редакциясендә)

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 345-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Тымытык авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының 2016 елның 10 июнендәге 32-14 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (15.11.2016 № 39-22, 25.09.2017 № 57-43, 12.02.2018 №52-74, 30.12.2019 №90-146, 14.04.2020 №95-157, 12.10.2021 №22-38, 07.04.2023 №45-85 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 бүлекнең 1 пунктында:

а) алтынчы абзацта «, газ бүлү челтәрләре, газ куллану челтәрләре һәм мондый челтәрләр объектлары» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац белән тулыландырырга:

«- газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләр объектларына карата «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 30.5 статьясында каралган башка шартлар;»;

в) сигезенче, тугызынчы абзацларны тугызынчы, унынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карар 2023 елның 23 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга:

http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Э.Х.Гыйләҗева